Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы карары

14.11.2017ел. № 68

2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге бюджеты проекты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм Яңасала авыл җирлеге Уставының 80, 81 статьяларына таянып, Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Б.Янгасал авылының Үзәк урамы 1 нче йортта урнашкан мәгълүмат щитларында бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге бюджеты проекты буенча 2018 елга һәм 2019-2020 елларның планлы чорына 2017 елның 8 декабрenә авыл мәдәният йорты бинасында сәгать 10да ачык тыңлауларны билгеләргә.
4. Бу карарның үтәлешен Яңасала авыл җирлеге башлыгы И. Х. Шиһабеевка контрольдә тотарга.

Кама Тамагы муниципаль районының
Яңасала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе
муниципаль район башлыгы И. Х. Шиһабеев